**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.07.2022 Балык Бистәсе штп. №155пи

Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "2015-2024 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру" муниципаль программасын раслау турында» 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015-2024 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 17.06.2022елның 17 июнендәге 577 номерлы карарына таянып, Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2015 - 2024 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 31 маендагы 80пи номерлы, 2016 елның 27 сентябрендәге 157пи номерлы, 2018 елның 24 сентябрендәге 230пи номерлы, 2019 елның 27 февралендәге 88пи номерлы, 2019 елның 16 сентябрендәге 275пи номерлы, 2020 елның 04 сентябрендәге 178 номерлы, 2021 елның 08октябрендәге 223пи номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2015 - 2024» саннарын «2015 - 2025» саннарына алмаштырырга;

преамбулада «2015 - 2024 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән» сүзләрен «2015 - 2025 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «2015-2024» саннарын «2015-2025» саннарына алмаштырырга;

күрсәтелгән карар белән расланган «2015 - 2024 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасында (алга таба - Программа):

исемендә «2015 - 2024» саннарын «2015 - 2025» саннарына алмаштырырга;

Программа паспортында: «Программа исеме» юлында «2015 - 2024» саннарын «2015 - 2025» саннарына алмаштырырга; «Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары» юлында «2015 - 2024» саннарын «2015 - 2025» саннарына алмаштырырга;

Программаның I бүлегендә:

өченче абзацта «2015 - 2024 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары» сүзләрен «2015 - 2025 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга;

Программаның II бүлегендә:

дүртенче абзацта «2024» санын «2025» санына алмаштырырга;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслауның гомуми күләме 2015-2025 елларда районның җирле бюджеты акчалары исәбеннән 616 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

| Ел | Районның җирле бюджеты акчалары күләме (мең сумнарда) |
|---|---|
| 2015 | 56 |
| 2016 | 56 |
| 2017 | 56 |
| 2018 | 56 |
| 2019 | 56 |
| 2020 | 56 |
| 2021 | 56 |
| 2022 | 56 |
| 2023 | 56 |
| 2024 | 56 |
| 2025 | 56 |

Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. Моннан тыш, программа чараларын гамәлгә ашыруга чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелгән акчаларны файдалану күздә тотыла»;

Программаның V бүлегендә:

беренче абзацта «2024» санын «2025» санына алмаштырырга;

икенче абзацта «2024» санын «2025» санына алмаштырырга;

2. . Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Житәкче Р.Л. Исланов